**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

____29.04.2022_____ г. Казань **№_______91од_______**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 11 мартындагы 01-02/170 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфалары коррупция куркынычы белән бәйле булган, шуңа күрә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмә тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 11 мартындагы 01-02/170 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфалары коррупция куркынычы белән бәйле булган, шуңа күрә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмә тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлегенә (2015 елның 22 декабрендәге 01-02/821 номерлы, 2016 елның 5 октябрендәге 01-02/265 номерлы, 2018 елның 9 гыйнварындагы 1од номерлы, 2018 елның 23 августындагы 91од номерлы, 2020 елның 4 декабрендәге146од номерлы, 2021 елның 27 сентябрендәге 123од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән), 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендә “белгечләр” категориясе:

җирле үзидарә һәм муниципаль регистр алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештыру һәм контрольне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча бүлекнең әйдәп баручы советнигы;

җирле үзидарә органнарына хокукый консультацион-методик ярдәм күрсәтү бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлегенең вазыйфасына адвокатлар тәкъдим иткән түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын каплау турында реестрларның тулылыгын һәм нигезлелеген тикшерүне гамәлгә ашыру кирә торган әйдәп баручы консультанты;

җирле үзидарә һәм муниципаль регистр алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлеге әйдәп баручы консультанты;

түләүсез юридик ярдәм күрсәтү һәм планлаштыру бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты.».

Министр вазыйфаларын башкаручы А.Г. Галимов